**УМК “Сәлам!”**

**4 нче сыйныф**

**«Бүген нәрсә пешерәбез?» темасы өстендә эш 2 нче дәрес**

**Рустелле төркемнәрдә татар теле дәресе**

Беренче квалификацион категорияле туган тел һәм әдәбияты укытучысы

Мансурова Л.С.

Дәреснең тибы: яңа материалны өйрәнү дәресе

Максат: 1. Рәсемнәрне тасвирлый алу. Тема буенча лексик берәмлекләрне һәм структураларны сөйләмдә дөрес куллана белү;

2. Фигыльләрне барлык һәм юклык формасында төрләндерә белү;

3. Коммуникатив күнекмәләрне үстерү.

4.Аралаша белү, бер-береңне ихтирам итәргә өндәү, активлык, бердәм эшли белү сәләтләрен тәрбияләү, дөрес туклану серләрен аңлауга ирешү

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

Метапредмет – эш тәртибен аңлап, уку эшчәлеген оештыра белү, уку максатын мөстәкыйль билгеләү, сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу, әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый белү

Предмет – рәсемнәрне тасвирлый алу, тема буенча лексик берәмлекләрне һәм структураларны сөйләмдә дөрес куллана белү;

Шәхескә кагылышлы – үз вакытыңны дөрес һәм файдалы итеп планлаштыра белү, җаваплылык тою.

Җиһазлар: карточкалар, интерактив такта, «Сәлам» сайты

Дәрес барышы

**1.** Оештыру моменты. Дәрескә уңай халәт тудыру.

Татар теле дәресен башлыйбыз! Һәрбер баланың хәлләрен сорашу.

**2.** Уку мәсьәләсен кую.

*ACTIVINSPIRE программасында биремне эшләү.*

кыздырылган бәрәңге – жареная картошка

пешкән ит – вареное мясо

солы боткасы – овсяная каша

дөге – рис

таба – сковорода

токмачлы аш – суп-лапша

кәстрүл – кастрюля

балык – рыба

- Монда нинди ашамлыклар бар?
- Монда нинди ярмалар бар?
- Монда нинди ризыклар бар?

- Монда нинди савыт-сабалар бар?

- Мин иртәнге ашка солы боткасы ашыйм һәм сөтле кофе эчәм. Төшке ашка кәбестә ашы һәм пешкән ит ашыйм, чәй эчәм. Кичке ашка  салат ашыйм һәм кефир эчәм.

- Ә  хәзер әйтегез, сез иртәнге ашка нәрсә ашыйсыз?

-Төшке ашка нәрсә ашыйсыз?

-Кичке ашка нәрсә ашыйсыз?

**-Бүген без нәрсә турында турында сөйләшәбез? Бүген дәрескә нинди бурычлар куябыз?**

( Иртәнге ашка, төшке ашка,  кичке ашка нәрсә ашыйбыз җөмләләрен әйтергә өйрәнәбез

3. Уку мәсьәләсен өлешләп чишү.
   **“Пинг-понг” уены. Тактада сүзләр белән эш.**
   Мин сүз әйтәм, ә сез бу сүзгә башка сүз әйтеп җөмлә төзегез
   Мәсәлән: Кисә. Маша кисә. Маша ипи кисә. Маша тәмле ипи кисә. Маша тәмле ак ипи кисә.
   **Ашый.**
   **Маша** ашый.
   Маша **карабодай боткасы** ашый.
   Маша **тәмле** карабодай боткасы ашый.
   Маша **иртәнге ашка** тәмле карабодай боткасы ашый.
   Маша иртәнге ашка тәмле карабодай боткасы ашый һәм **чәй эчә.**
   Маша иртәнге ашка тәмле карабодай боткасы ашый **һәм** **баллы** чәй эчә.
   Маша **сәгать җидедә** иртәнге ашка тәмле карабодай боткасы ашый һәм баллы чәй эчә.
4. **“Ах, хуш ис кайдан килә”** җырын бергә җырлау.

5. **Дәреслектәге рәсемнәр белән эш. “Сәлам” сайты**
   -Беренче рәсемдә нинди аш вакыты?
   -Кыз иртәнге ашка нәрсә ашый? (Кыз  иртәнге ашка солы боткасы, ипи сыр һәм май белән ашый, какао эчә)
   -Икенче рәсемдә нинди аш вакыты? (Төшке аш)
   -Бу кем? Малай төшке ашка нәрсә ашый? (Малай төшке ашка салат, аш, макарон, ит ашый һәм сок эчә)
   -Өченче рәсемдә нинди аш вакыты?
   -Бу кем? Ул кичке ашка нәрсә ашый?( Ул кичке ашка кыздырылган тавык ите, яшел борчак ашый, десерт белән чәй эчә)

***Күзләргә физкультминутка***

**Күзләр белән тәрәзәгә карагыз**
**Ишеккә карагыз**
**Түшәмгә карагыз**
**Идәнгә карагыз**
**Күзләр белән түгәрәк ясагыз, өчпочмак ясагыз, күзләрегезне йомыгыз, күзләрегезне ачыгыз**

**Дәреслектәге текстларны уку.**
-Беренче текст кайсы рәсемгә туры килә?
-Икенче текст кайсы рәсемгә туры килә?
-Өченче текст кайсы рәсемгә туры килә?

6. **Әзерли сүзен барлык һәм юклык формаларында затларда һәм саннарда төрләндерү**

*ACTIVINSPIRE программасында биремне эшләү.*
**Әзерли - готовит**
**Мин әзерли-м**
**Син әзерли-сең**
**Ул әзерли**
**Без әзерли-без**
**Сез әзерли-сез**
**Алар әзерли-ләр**

7. Юклык формасындагы әзерләми дигән сүзне карточкаларда эшләгез.

| | | |
|---|---|---|
| Мин әзерләми | | -сең |
| Син әзерләми | | -ләр |
| Ул әзерләми | | -м |
| Без әзерләми | | -сез |
| Сез әзерләми | | - |
| Алар әзерләми | | -без |

8. **Өй эше**
81 нче бит 4 нче күнегүне укырга, сораулар әзерләргә (2-3 сорау);
* III заттан укырга
8. **Рефлексия**

- Ребята, как вы оцениваете свою работу на уроке?
- У кого были затруднения? Какие трудности встретились?
- Какие задания вам понравились больше всего?
- За что вы можете себя похвалить?
- За что вы можете похвалить своих одноклассников? Кто сегодня лучше всех работал? (Выставление оценок.)
- **Похвалите друг друга. Используйте слова: акыллы, җаваплы, зирәк, тырыш.**

**Сез бик акыллы кызлар һәм малайлар! Сезгә уңышлар телим!**